МИНИСТЕРСТВО
СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Федосеевская, дом 36, г. Казань, 420014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ
ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК
МИНИСТРЛЫГЫ
Федосеевская ур., 36 йорт, Казан ш., 420014

Тел.: (843) 221 76 00, факс: (843) 221 76 79, agro@tatar.ru, www.agro.tatar.ru

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.11.2023 г. Казань № 411/2-пр

2023 елда «Иң яхшы комбайнчы»
республика конкурсын
уздыру турындагы нигезләмәне
раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 4 сентябрендәге 1975-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә, урып-җыю эшләрен вакытында һәм сыйфатлы башкару, комбайнчыларның һөнәри камилләшүенә өстәмә кызыксындыру булдыру, һөнәрнең абруен һәм иҗтимагый әһәмиятен күтәрү максатларында, б о е р а м:

1. 2023 елда «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсын уздыру турындагы нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары Л.Н. Гариповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер министры урынбасары – министр М.А. Җәббаров

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2023 елның 10 ноябрьдәгэ 411/2-пр номерлы боерыгы белән расланды

2023 елда «Иң яхшы комбайнчы»
республика конкурсын уздыру турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2023 елда «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсын уздыру турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) 2023 елда «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсын уздыруның һәм оештыруның максатын, тәртибен билгели.

1.2. 2023 елда «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсын (алга таба – конкурс) уздыруның максаты - Татарстан Республикасы территориясендә урып-җыю кампаниясе барышында ашлык суктыру, терлек азыгы әзерләү һәм чаптыру мәйданы буенча югары күрсәткечләргә ирешкән аеруча актив комбайнчыларны бүләкләү.

1.3. Конкурсны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) оештыра.

1.4. Конкурсны уздыру сроклары, шартлары турындагы мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында (https://agro.tatarstan.ru) «Белгечләр өчен мәгълүмат» бүлегендә (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) әлеге боерык үз көченә кергән көннән өч календарь көн эчендә урнаштырыла.

1.5. Конкурсны финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 4 сентябрендәге 1975-р номерлы күрсәтмәсендә каралган акчалар исәбенә Министрлык тарафыннан башкарыла.

1.6. Конкурсны уздыру түбәндәге принципларга нигезләнә:
гавамилек һәм ачыклык;
конкурста катнашучыларның тигезлеге.

## 2. Конкурста катнашу тәртибе

2.1. Конкурста катнашуга Татарстан Республикасы территориясендә ашлык җыю комбайннарында, азык җыю комбайннарында, үзйөрешле чапкычларда һәм теземгә салучы ургычларда эшләүчеләр (алга таба - хезмәткәрләр), авыл хуҗалыгы эшчәнлеген алып баручы теләсә нинди оештыру-хокукый рәвешендәге оешмаларда, крестьян (фермер) хуҗалыкларында, шәхси эшкуарларда хезмәт итүчеләр (алга таба - авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре) кертелә.

2.2. Конкурста катнашу өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Татарстан Республикасы муниципаль районында үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча Министрлыкның тиешле Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба - Идарә) 2023 елның 27 ноябренә кадәр түбәндәге документларны тапшыралар:

хезмәткәр паспортының күчермәсен;

хезмәткәр белән төзелгән хезмәт шартнамәсе күчермәсен йә хезмәткәр һәм авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре арасындагы хезмәт мөнәсәбәтләрен раслый торган башка документның күчермәсен;

суктырылган ашлыкка, азык әзерләүгә йә экипажлар чаптырган мәйданнарга уздырылган мониторинг буенча Нигезләмәгә 1нче кушымтадагы формада әзерләнгән хисапны;

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар һәм җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча хезмәткәрнең үтәлмәгән бурычлары булмавын раслый торган салым органы белешмәсен;

хезмәткәрнең үзе турындагы шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалыгын, тәкъдим ителә торган форма әлеге Нигезләмәгә 3нче кушымтада китерелгән;

хезмәткәрнең тарату өчен рөхсәт ителгән үзе турындагы шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалыгын, тәкъдим ителә торган форма әлеге Нигезләмәгә 4нче кушымтада китерелгән.

2.3. Нигезләмәнең 2.2 пунктының дүртенче абзацы нигезендә тапшырылган документларның һәм белешмәләрнең дөреслеге өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре җаваплы була.

2.4. Хезмәткәрләр түбәндәге очракларда конкурста катнашуга кертелми:

Нигезләмәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән документларны Идарәгә Нигезләмәнең 2.2 пунктында билгеләнгән сроктан соң тапшырганда;

Нигезләмәнең 2.2 пунктында билгеләнгән документларны тапшырмаганда яисә тулы күләмдә тапшырмаганда;

тапшырылган документларда тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган белешмәләр булганда.

2.5. Идарә тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча беркетмә төзи, анда хезмәткәрне конкурста катнашуга кертү яисә кертмәү турында мәгълүмат чагылдырыла (алга таба – гаризаларны карау буенча беркетмә).

2.6. Идарә 2023 елның 4 декабренә кадәр Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

гаризаларны карау буенча беркетмә;

ашлык суктыруга, азык әзерләүгә һәм экипаж чаптырган мәйданнарга уздырылган мониторинг хисапларының Нигезләмәгә 1нче кушымтадагы форма буенча җыелма реестры;

Нигезләмәнең 2.2 пункты нигезендә тапшырылган шәхси белешмәләрне эшкәртүгә хезмәткәрләрнең ризалыгы (3 нче кушымта буенча) ;

Нигезләмәнең 2.2 пункты нигезендә тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси белешмәләрне эшкәртүгә хезмәткәрләрнең ризалыгы (4 нче кушымта буенча).

2.7. Министрлык идарә тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә ашлык суктыру, азык әзерләү күләмнәре һәм чаптыру мәйданы буенча белешмәләрне анализлый, шулай ук аларны сортларга аера һәм түбәндәге күрсәткечләр буенча рейтинг төзи:

ашлык җыю комбайннары төркеме буенча – Татарстан Республикасында суктырылган бөртекле, кузаклы культураларның максималь күләме буенча, Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә, дүрт төркем комбайннар буенча;

азык җыю комбайннары буенча – Татарстан Республикасында әзерләнгән сенаж һәм силосның максималь күләме буенча, Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә, өч төркем комбайннар буенча;

үзйөрешле чапкычлар һәм теземгә салучы ургычлар буенча – Татарстан Республикасында чаптырылган бөртекле, кузаклы һәм техник культураларның максималь күләме буенча, Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә.

## 3. Конкурсны уздыру тәртибе

3.1. Конкурста җиңүчеләрне билгеләү өчен конкурс комиссиясе (алга таба - комиссия) төзелә, ул Нигезләмәнең 2.6 пункты нигезендә кергән документларны карый.

3.2. Конкурс комиссиясе составы Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия составына аның рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм комиссия әгъзалары керә. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара. Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокуклы булалар.

3.3. Комиссия рәисе комиссия утырышының көн тәртибен раслый, комиссия утырышын уздыру урынын һәм вакытын билгели, комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә, комиссия утырышын үткәрә. Комиссия секретаре комиссия утырышын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында комиссия әгъзаларына хәбәр итә, комиссия утырышларына материаллар әзерли, комиссия утырышларының беркетмәләрен төзи.

3.4. Комиссия эше утырышлар рәвешендә башкарыла. Утырыш, әгәр анда комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, вәкаләтле булып санала. Комиссия тарафыннан карарлар комиссия утырышында катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, комиссия утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

3.5. Комиссия карары комиссия утырышы беркетмәсе итеп рәсмиләштерелә. Комиссия утырышы беркетмәсе комиссия утырышы узган көннән алып өч эш көне эчендә рәсмиләштерелә.

3.6. Комиссия утырышы 2023 елның 11 декабреннән дә соңга калмыйча уздырыла.

3.7. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

Республика башкарма хакимияте органнарыннан, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан комиссия эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

тапшырылган мәгълүматның дөреслеген тикшерергә;

үз утырышларына республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары вәкилләрен, оешмалар җитәкчеләрен комиссия компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен чакырырга.

3.8. Комиссия 490 кешене конкурста җиңүчеләр буларак билгели һәм гомуми күләме 20,0 млн. сум булган премияне алар арасында түбәндәге күләмнәрдә бүлә:

конкурста ашлык җыю комбайннары төркеме буенча бер җиңүчегә 50,0 мең сум күләмендә 190 премия - Татарстан Республикасында суктырылган бөртекле, кузаклы культураларның максималь күләме буенча;

конкурста азык җыю комбайннары төркеме буенча бер җиңүчегә 50,0 мең сум күләмендә 50 премия - Татарстан Республикасында әзерләнгән сенаж һәм силосның максималь күләме буенча;

конкурста үзйөрешле чапкычлар һәм теземнәргә салучы ургычлар төркеме буенча бер җиңүчегә 40,0 мең сум күләмендә 50 премия - Татарстан Республикасында чаптырылган бөртекле, кузаклы һәм техник культураларның максималь күләме буенча.

Татарстан Республикасында бөртекле һәм кузаклы культураларны урып-җыюның гомуми мәйданында муниципаль районның чагыштырма күләмен исәпкә алып, конкурста Татарстан Республикасы муниципаль районнары арасында бер җиңүчегә (әлеге пунктның икенче, өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән конкурста җиңүчеләрдән тыш) 30,0 мең сум күләмендә 200 премия һәм ул Татарстан Республикасында сукутырылган бөртекле, кузаклы культураларның максималь күләме буенча бәяләнә.

Премияләр күләме физик затның кеременә салым суммасы тотылуны исәпкә алмыйча күрсәтелгән.

3.9. Конкурс йомгаклары комиссия утырышы беркетмәсе имзаланган датадан өч эш көне эчендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

3.10. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү Министрлык тарафыннан, 2023 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча, премияләрне җиңүчеләрнең исәп-хисап счетларына күчерү өчен Нигезләмәнең 3.8 пункты нигезендә Идарәләрнең исәп-хисап счетларына күчерү юлы белән башкарыла.

2023 елда “Иң яхшы комбайнчы” республика конкурсын уздыру турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта

2023 ел уңышын урып-җыюда иң яхшы комбайнчылар турында мәгълүмат (бөртекле һәм кузаклы культуралар)

| ТР муниципаль районы | Хуҗалык | Комбайн-чының Ф.И.АТ.ис. *(атасының исеме – булса)* | Комбайн төркеме | Комбайн-ның маркасы | Комбайн-ның чыгарыл-ган елы | Суктыру-да эшләгән көннәр саны | Урып-җыю башыннан алып соңгы көнгә кадәр булган күрсәткеч | | шул исәптән бер көн эчендә | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | суктырылган ашлык, тн | суктырылган мәйдан, га | суктырылган ашлык, тн | суктырылган мәйдан, га |
| | | | 1 төркем | | | | | | | |
| | | | 2 төркем | | | | | | | |
| | | | 3 төркем | | | | | | | |
| | | | 4 төркем | | | | | | | |

2023 елда азык әзерләүдә иң яхшы комбайнчылар турында мәгълүмат

| ТР муниципаль районы | Хуҗалык | Комбайн-чының Ф.И.АТ.ис. *(атасының исеме – булса)* | Комбайн төркеме | Комбайн-ның маркасы | Комбайн-ның чыгарыл-ган елы | Суктыру-да эшләгән көннәр саны | Урып-җыю башыннан алып соңгы көнгә кадәр булган күрсәткеч | | шул исәптән бер көн эчендә | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | әзерләнгән, тн | җыелган, га | әзерләнгән, тн | җыелган, га |
| | | | 1 төркем | | | | | | | |
| | | | 2 төркем | | | | | | | |
| | | | 3 төркем | | | | | | | |

2023 елда чапкычларда иң яхшы механизаторлар турында мәгълүмат

| ТР муниципаль районы | Хуҗалык | Комбайн-чының Ф.И.АТ.ис. *(атасының исеме – булса)* | Агрегатның маркасы | Чапкыч-ның чыгарыл-ган елы | Чакычта эшләгән көннәр-нең гомуми саны | Урып-җыю башыннан алып соңгы көнгә кадәр булган күрсәткеч | шул исәптән бер көн эчендә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | бөртеклеләр, га | бөртеклелеләр, га |
| | | | | | | | |

2023 елда “Иң яхшы комбайнчы” республика
конкурсын уздыру турындагы нигезләмәгә
2 нче кушымта

Ашлык җыю комбайннарын 2023 елда “Иң яхшы комбайнчы” республика конкурсында катнашу өчен төркемнәргә бүлү

| Комбайн-ның классы | Комбайннарның маркасы | Двигателенең куәте, ат көче | Җитеште-рүчәнлеге, га/смена | Үткәрү мөмкинлеге, кг/сек |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Енисей-1200 | 140 | 12 | 7,1 |
| | СК-5 «Нива» | 145 | 12 | 5,7 |
| | Вектор-410 | 209 | 16 | 7,7 |
| | Вектор-420 | 209 | 16 | 7,8 |
| | Массей Фергюссон-5650 | 180 | 15 | 7 |
| | Нова-320 | 180 | 14 | 6,2 |
| | КЗС-7 | 210 | 20 | 7,8 |
| | КЗС-812 | 230 | 22 | 7,8 |
| 2 | ДОН-1500 | 230 | 20 | 9,5 |
| | ДОН-1200 | 220 | 20 | 9 |
| | Лида-1300 | 250 | 25 | 9 |
| | Акрос-530 | 250 | 26 | 12 |
| | Акрос-550 | 280 | 27 | 12 |
| | КЗР-10 «Полесье» | 290 | 22 | 10,9 |
| | КЗС-10К | 250 | 22 | 10 |
| | Кейс-2366 | 239 | 22 | 13 |
| | Клаас МЕГА-204 | 245 | 22 | 8,2 |
| | Клаас МЕГА-208 | 260 | 24 | 8,2 |
| | Нью Холланд ТС-56 | 240 | 22 | 7,6 |
| | Нью Холланд ТХ-65 | 280 | 26 | 9 |
| | Сампо-3065 L | 260 | 17 | 10 |
| | Нью Холланд ТХ-68 | 290 | 22 | 10 |
| | Класс Доминатор-370 | 205 | 20 | 8 |
| | Клаас Мега-360 | 245 | 25 | 8,2 |
| | Клаас Мега-370 | 260 | 26 | 8,2 |
| | Джон Дир W 540 | 255 | 24 | 8 |
| | Джон Дир 9640 | 275 | 26 | 12,5 |
| | Челленджер СН 647 С | 276 | 25 | 10 |
| | Акрос-580 | 300 | 28 | 12 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3 | Акрос-585 | 300 | 28 | 12 |
| | Акрос-595 | 325 | 34 | 15 |
| | КЗС-1218 (GS 12) | 326 | 30 | 12,8 |
| | Сампо Комия С12 | 300 | 30 | 8 |
| | Нью Холланд СХ 840 | 300 | 30 | 8 |
| | Нью Холланд CSX | 300 | 30 | 7,6 |
| | Нью Холланд СХ | 326 | 30 | 8,6 |
| | Нью Холланд CS | 300 | 27 | 7,6 |
| | Клаас Тукано -430 | 300 | 30 | 8,2 |
| | Клаас Тукано -450 | 300 | 30 | 8,2 |
| | Клаас Тукано -470 | 326 | 32 | 15 |
| | Клаас Тукано -480 | 326 | 32 | 15 |
| | Клаас Лексион -480 | 312 | 36 | 15,8 |
| | Клаас Лексион -540 | 312 | 36 | 15,8 |
| | Джон Дир-9560 | 305 | 28 | 9,5 |
| | Джон Дир-9660 | 338 | 28 | 9,5 |
| | Джон Дир-9670 | 300 | 30 | 10 |
| | Джон Дир-9750 | 310 | 30 | 12 |
| | Массей Фергюссон-7347 | 306 | 24 | 11 |
| 4 | РСМ-161 | 360 | 34 | 12 |
| | Клаас Тукано-570 | 378 | 34 | 12 |
| | Клаас Тукано-580 | 378 | 34 | 12 |
| | Челленджер 654В | 378 | 34 | 12 |
| | Торум-740 | 420 | 36 | 14 |
| | Торум-750 | 425 | 38 | 15 |
| | Торум-785 | 510 | 44 | 17 |
| | Клаас Лексион - 550 | 351 | 25 | 12 |
| | Клаас Лексион - 560 | 400 | 40 | 13 |
| | Клаас Лексион - 570 | 400 | 40 | 13 |
| | Клаас Лексион - 580 | 400 | 40 | 13 |
| | Клаас Лексион - 650 | 419 | 42 | 15 |
| | Клаас Лексион - 670 | 419 | 42 | 15 |
| | Клаас Лексион - 740 | 523 | 48 | 16 |
| | Клаас Лексион - 770 | 523 | 48 | 19,5 |
| | Полесье GS3219 | 390 | 35 | 12 |
| | Полесье GS16 | 530 | 48 | 16 |

2023 елда урып-җыю эшләренә җәлеп ителгән
азык җыю комбайннары төркеме

| Комбайн-ның классы | Комбайннарның маркасы | Двигателенең куәте, ат көче | Җитештерүчәнлеге, т/сәгать |
|---|---|---|---|
| 1 | К-Г-6 "Полесье" | 250-280 | 90 |
| | КСК 600 | 240 | 108 |
| | Дон 680 | 290 | 110 |
| 2 | КВК 800 | 450 | 130 |
| | РСМ 1401 | 495 | 140 |
| | Ягуар 810 | 299 | 115 |
| | Ягуар 830-840 | 321-407 | 120-130 |
| | Ягуар 850-870 | 398-438 | 132-140 |
| | Джон-Дир | 450-460 | 132-138 |
| 3 | РСМ F2650 | 643 | 200 |
| | Ягуар 970-980 | 775-884 | 230-250 |
| | Нью-Холланд | 578-824 | 160-220 |
| | Кроне | 650-980 | 150-300 |

2023 елда урып-җыю эшләренә җәлеп ителгән
үзйөрешле чапкычлар төркеме

| Комбайн-ның классы | Чапкычларның маркасы | Двигателенең куәте, ат көче | Җитештерүчәнлеге, га/сәгать |
|---|---|---|---|
| 1 | МакДон | 150 | 7 |
| | Челленджер | 120 | 5 |
| | Джон Дир | 110 | 6 |
| | Кейс | 120 | 6 |
| | Нью Холланд | 120 | 6 |
| | Массей Фергюссон | 85 | 5 |
| | ЕС-1 | 155 | 4,5 |
| | КСУ-1 | 157 | 4,5 |
| | Мещера Е-403 | 88 | 4 |
| | CS-200 | 200 | 7,6 |

2023 елда “Иң яхшы комбайнчы” республика
конкурсын уздыру турындагы нигезләмәгә
3 нче кушымта
(Тәкъдим ителә торган форма)

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә
РИЗАЛЫК

Мин,_______________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса)
шәхесне таныклаучы документ:
_____________________________________________________________________
(документ төре)
документның сериясе, номеры:______________________________ бирелү датасы
_____________________________________________________________________
аны биргән орган: ____________________________________________________
_____________________________________________________________________,
яшәү урыны
адресы:______________________________________________________________
_____________________________________________________________________,
Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык), Министрлыкның юридик адресы: 420014, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Федосеев ур., 36 йорт,
_____________________________________________муниципаль районында
(муниципаль район исеме)
Министрлыкның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә, Идарәнең юридик адресы:______________________________________________________________
2023 елда «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсында катнашу максатында үземнең шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган шәхси белешмәләр исемлеге: фамилиясе, исеме, атасы ис. (булса), туу датасы, паспорт белешмәләре (шәхесне раслаучы башка документның белешмәләре) паспортта (шәхесне раслаучы документта) булган шәхси белешмәләр, яшәү урыны адресы, эш урыны адресы, элемтә телефоны (өй, мобиль, эш), салым түләүченең идентификация номеры, шулай ук хезмәт шартнамәсендә (хезмәт мөнәсәбәтләрен раслаучы документта) булган башка шәхси белешмәләр, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча түләнмәгән бурычлар булмавы турында салым органы белешмәсе.

Шәхси белешмәләр белән эш итүгә ризалык бирелә торган гамәлләр исемлеге: автоматлаштырылган чаралар кулланып яисә андый чаралар кулланмыйча шәхси белешмәләр белән башкарыла торган теләсә нинди гамәл (операция) яки гамәлләр (операцияләр) җыелмасы, шул исәптән шәхси белешмәләрне җыю, яздыру, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), өйрәнү, куллану,

тапшыру (тарату, бирү, файдалану), шәхеснең кемлеген яшерү, блокировкалау, алып ату, юкка чыгару.

Әлеге килешү ул имзаланган датадан биш ел дәвамында гамәлдә була.

«Шәхси белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре белән танышуымны раслыйм, шәхси белешмәләрне яклау өлкәсендәге хокуклар һәм бурычлар миңа аңлатылды, әлеге ризалык теләсә кайсы вакытта Министрлыкка һәм (яисә) Идарәгә язылган минем гариза буенча кире алынырга мөмкин булуы да миңа билгеле.

Имза:______________________________

Дата: ______________________________

2023 елда “Иң яхшы  комбайнчы” республика
конкурсын уздыру  турындагы нигезләмәгә
4 нче  кушымта
(Тәкъдим ителә торган  форма)

Тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси белешмәләрне эшкәртүгә
РИЗАЛЫК

Мин,_______________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса)
шәхесне таныклаучы документ: ____________________________________________
(документ төре)
документның  сериясе, номеры:______________________________бирелү датасы:
_____________________
аны  биргән орган:__________________________________________________________
яшәү урыны адресы: _________________________________________________________
__________________________________________________________________________,

“Шәхси белешмәләр турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 10.1 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык), ИНН 1654019555, Министрлыкның юридик адресы: 420014, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Федосеев ур., 36 йорт,

_______________________________________________муниципаль районында
(муниципаль район исеме)
Министрлыкның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба - Идарә), ИНН___________________, Идарәнең юридик адресы:
__________________________________________________________________________
(алга таба – бергә “оператор” дип атала)

2023 елда «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсында катнашу максатында үземнең шәхси белешмәләрне таратуга (тапшыруга, бирүгә, файдалануга) ризалыгымны бирәм.

1. Эшкәртүгә ризалык бирелә торган шәхси белешмәләр   исемлеге:

| № т/с | Шәхси белешмәләр | Ризалык | |
|---|---|---|---|
| | | ӘЙЕ | ЮК |
| 1. | Фамилиясе | | |
| 2. | Исеме | | |
| 3. | Атасының исеме (булса) | | |
| 4. | Туган елы, ае, көне | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5. | Адресы | | |
| 6. | Белеме | | |
| 7. | Һөнәре | | |

2. Эшкәртү өчен шартлар һәм тыюлар билгеләнә торган шәхси белешмәләр исемлеге:

| № т/с | Шәхси белешмәләр | Билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге |
|---|---|---|
| 1. [Шәхси белешмәләр категориясе] | | |
| | [Шәхси белешмәләр исемлеге] | |

Әлеге ризалыкның 2 пункты шәхси белешмәләр субъекты теләге буенча шәхси белешмәләрне эшкәртүче оператор ягыннан чикләүләр куелмыйча тутырыла. Шартлар һәм тыюлар шәхси белешмәләрне чикләнмәгән яисә аерым бер даирәдәге затларга оператор тарафыннан тарату һәм (яисә) бирү гамәлләрен чикләүне яисә тыюны күздә тота.

Алынган шәхси белешмәләр аларны эшкәртүче оператор тарафыннан аның үзенең бары тик катгый билгеләнгән хезмәткәрләр өчен генә файдалана алуны тәэмин итә торган эчке челтәре аша йә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып, йә алынган шәхси белешмәләрне тапшырмыйча гына таратылырга мөмкин (шәхси белешмәләр субъекты теләге буенча тутырыла).

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________.

Операторның чикләнмәгән затлар даирәсенә файдалануга тапшыру һәм шәхси белешмәләр субъектының шәхси белешмәләре белән башка гамәлләр кылу мөмкинлеген бирә торган мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр: https://agro.tatarstan.ru.

Әлеге ризалыкның гамәлдә булу срогы: ____________________________
____________________________(ризалыкның гамәлдә булуының төгәл срогын күрсәтергә)

Тарату өчен шәхси белешмәләр субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән шәхси белешмәләрне тапшыру (тарату, бирү, файдалану) шәхси белешмәләр субъектының оператор адресына бирелгән язма таләбе буенча теләсә кайсы вакытта туктатылырга тиеш.

Имза:____________________________
Дата: ____________________________